**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**СТАРОАЛЬМЕТЬЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НУРЛАТСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН**
**РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ИСКЕ ӘЛМӘТ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Иске Әлмәт ав. **КАРАР**

«8» апрель 2021 ел № 1

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Иске Әлмәт авылында гражданнар җыенында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 19 нчы апрель көнне сәгать 10.00га Иске Әлмәт авылы, Октябрь урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан Иске Әлмәт мәдәният йорты бинасында түбәндәге элек расланган карарларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча Иске Әлмәт авылында яшәүче гражданнар җыенын билгеләргә:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 11.11.2020г. № 1 номерлы карар;

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт торак пунктында гражданнар җыенының 11.11.2020г. № 2 номерлы карарына.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылында халык җыенын үткәрү һәм оештыру белән Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты шөгыльләнә дип билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлегенең Иске Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында элегрәк расланган һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлегенең Иске Әлмәт торак пунктында гражданнар җыенының 11.11.2020 ел, 2 нче номерлы карарына киләсе үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелү белән килешәсезме?:

Иске Әлмәт авыл җирлеге территориясендә, 1 гр. инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге формада белем алучы студентлардан, яшәү урыны буенча теркәлгән, әмма яшәү урыны буенча яшәмәүче гражданнардан кала, яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2021 елда үзара салым тәртибендә җыелган 1000 сум күләмендәге үзара салым, югарыда күрсәтелгән карарлар белән расланган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән эшләр исемлеген, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- янгынга каршы инвентарь алу.
- Иске Әлмәт торак пунктының 62 нче скважинасы янындагы территорияне төзекләндерү, су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча ремонт эшләре үткәрү.
- Нариманов исемендәге торак пунктны төзекләндерү»

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында района http://nurlat.tatarstan.ru/rus/st_almetevskoe.htm/, Иске Әлмәт авыл җирлегенең Иске Әлмәт авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов